| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**24 августа 2016 г.**

Зеленодольск ш.

**КАРАР**
**№ 2243**

Зеленодольск районы, Норлат авылы, Яктылык ур., 1 йорт адресы буенча урнашкан җир кишәрлеген алу турында

Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә 2013-2017 елларга Зеленодольск муниципаль районында гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча муниципаль адреслы программаны тормышка ашыру максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 26.09.2013 елның 2178 номерлы карары белән расланган, 21.07.2007 ел, «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итү фонды турында" №185-ФЗ Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Торак кодексы, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Муниципаль ихтыяҗлар өчен Зеленодольск районы, Норлат авылы, Яктылык урамы, 1 йорт адресы буенча җир кишәрлеген, шулай ук күрсәтелгән йортта урнашкан күчемсез милек объектларын (кушымтада) алырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайты (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә һәм «Зеленодольская правда" газетасында урнаштырырга.
3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О. А. Матвеевага әлеге карарның күчермәсен:
• чыгарыла торган күчемсез милекнең хокук ияләренә;
• күчемсез милеккә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы органга;
• МКУ "Торак сәясәте департаменты»на җибәрергә.
4. МУ «Зеленодольск муниципаль районы җир мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлеген урнаштыру схемасын раслауны тәэмин итәргә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче А. Х. Сәхибуллин

Зеленодольск муниципаль
районы Башкарма комитетының
2016 елның 24 августы, №2243
карарына  кушымта

Зеленодольск муниципаль районы, Норлат авылы, Яктылык урамы, 1 нче номерлы күпфатирлы торак йортта , урнашкан, авария хәлендә һәм сүтелергә тиешле күчемсез милек объектлары (торак, торак булмаган биналар) исемлеге

| № кв. |
| --- |
| 4 |